**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**Нижнеалькеевского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Түбән Әлки авыл җирлеге**

**СОВЕТЫ**

Адрес: 422881, РТ, с. Нижнее Алькеево
ул. Советская, д. 55
тел. 8 (84346) 77-2-15

Адресы: 422881, РТ, Тубэн Элки авылы, Совет ур., 55
факс: 8 (84346) 77-2-15

РЕШЕНИЕ Түбән Әлки авылы КАРАР

2024 елның 16 мае 59№

Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советының 2021 елның 30 нояберендәге «Җир салымы турында» 38 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон , 2023 елның 31 июлендәге "Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында»389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советының 2021 елның 30 ноябрендәге «Җир салымы турында» 38 номерлы карарына үзгәрешләр кертү (яңа ред. 2022.11.04 10 №) хакында карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 статьяның 3 абзацын яңаредакциядә бәян итәргә:

“-0,3% торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә (торакфондынаһәм (яисә) тораккоммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясеннән торак төзелеше(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)".

4 статьяны 8 абзац белән тулыландырырга) түбәндәге эчтәлектә:

8) рөхсәт ителгән куллану төре белән:

16:06:080501:33 кадастр номерлы торак төзелеше өчен;

- 16:06:080101:1361, 16:06:080101:1362 кадастр номерлары белән җитештерү базаларын урнаштыру өчен;

2.Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http:pravo.tatarstan.ru порталында урнаштырырга.

Әлки муниципаль районының
Түбән Әлки авыл җирлеге Советы рәисе урынбасары: Ф.Ф.Мисалов